# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2004, № 3 (I өлеш), № 4 – 5, № 10, № 11; 2005, № 7 – 8, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 5 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2009, № 6, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

"8) оешмалар – сәламәтлек саклау, физик тәрбия һәм спорт ихтыяҗлары өчен, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата. ";

б) 3 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) оешмалар – мәдәният һәм сәнгать, мәгариф, социаль тәэминат ихтыяҗлары өчен, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата.";

2) 5 статьяның 6 пунктында "2 – 5,7" саннарыннан соң ", 8" санын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2012 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 24 феврале
№ 12-ТРЗ